Кадерле Девятерня авылы жирлеге гражданнары,

хөрмәтле Ришат Тимерович, килгән кунаклар!

Гадәттәгечә ел башыннан һәр уткән елга эшләгән эшләргә нәтиҗә ясала, алдагагы елга бурычлар , йокләмәләр билгеләнә .Шулай ук, авыл жыенында район житәкчелеге,учреждение һәм оешма специалистлары тарафыннан халыкны кабул иту оештырыла ,аларны борчыган төрле сорауларга жаваплар ,кинәшлэр бирелә.

2012 ел дәверендә Девятерня авыл жирлеге узенең эшен Россия Федерацияце законнарына , авыл жирлеге Уставына нигезләнеп башкарды .

Авылны төзекләндеру, авыл жирлегендә урнашкан учреждениеләр эшен оештыру ,халыкны су, ут белән тәэмин итү,җирле салымнарны жыю,төрле бәйрәм чараларын уздыру һәм башка төрле күп эшләр эшлэнде.

2012 ел дәвамында авыл жирлегенә төрле сораулар белән 656 кеше мөрәжагәт иткән,һәр кабул иткэн гражданнарның сорауларын вакытында тиешенчә хэл итәргә тырыштык. Үтенечләр күп төрле: хезмәт стажын барлау,тиешле льготалар,кредит турында белешмәләр,гаилә хәле,яшәу урыны турында справкалар хәм башкалар. Халык белән тыгыз элемтәдә булырга тырышабыз,кабул иту вакыты белән чутлашмыйбыз,кирәк икән ял сәгатен дә, ял көнендә кабул итәбез.

Девятерня авыл жирлегендә 2012 елның 1 январенә 357 хужалык, 665 кеше исәпләнә.

| | хужалык | халык | пенсионер | эшләмәүчеләр | студентлар | 17 яшькә кадәр балалар |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Девятерня | 175 | 425 | 136 | 28 | 17 | 88 |
| Нарат | 84 | 181 | 70 | 21 | 8 | 19 |
| Гали | 22 | 58 | 16 | 5 | 5 | 18 |
| Комсомолка | 1 | 1 | - | - | - | - |
| Барлыг | 28 | 66 | 222 | 54 | 30 | 125 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| ы | 2 | 5 | | | | |

Безнең авыл жирлегедә 1 сугыш ветераны, 69 хезмәт ветераны, һәм тыл ветераны. Ирләре сугышта катнашкан, тол калган апалар 18 кеше исәпләнә,. 2012 елда 1 бала туган, 20 кеше вафат булган, 1 пар никах теркәлгән,. Ел саен без саннарны чагыштырабыз . Халык саны артуга бармый, аяныч. Бу безнең авыл жирлегенә генә кагылмый, башка жирдә дэ шул ук хәл. Авылда яшьләрнең бик каласы килми, чөнки хужалык алып барыр өчен мөмкинленкләр булса да кубесенә» достойный» эш юк. Калганнары да нигәдер бик эшләргә, гаилә корырга атлыгып тормый. Алдагы көндә эти-әнисез ничек яшәүләрен уйламыйлар.

Авыл жирендә яшәгән халык ул мал асрамыйча, яки башка эш белән шөгылләнмичә яши алмый . Хәзерге заманда бигрәк тә. Кайбер гаиләләр доходны уз хужалыклары хисабына гына алалар.

Девятерня авылы жирлегенең хужалык кенәгэсендә барлыгы 280 эре мөгезле терлек санала,106 баш сыер ,142 баш сарык- кәжә, 28 баш ат, 702 баш умарталык теркәлгән. Маллар санында узгэрешләр булып тора: кемдер сата,кемдер сатып ала,кемнәрдер налог туләмәс өчен мал санын яшерә( төрле кешеләр бар) .

Ел азагында күп кенә хуҗалыкларда сыер саны кимеде,моның төрле сәбәпләре бар, мал асрарга мөмкинлеге булмаган кешеләр бар,сөтнең бәясе юк диючеләр дә бар. Чыннан да, бәясе түбән, иптэшләр. 2010 елда сөтнең уртача тапшыру бәясе 9сум 50 тиен булса, 2012 елда 7сум 50 тиен калган.

Бүгенге көндә авыл халкының өстәмә табышын арттыру, эшсезлекне киметү максатында төрле программалар эшләп килә. ЛПХ линиясе буенча льготалы кредитлар бирелә. Бездә 8 кеше 780 меңлек кредит алган , бу акчалар мал һәм корт алу, каралты кура житкерү,техника жихазлары алу өчен тотылды .

Гаилә фермалары оештыру буенча программа эшләп килә.

Безнең авыл җирлеге территориясендә дә Гали авылында гаилә фермасы эшләп килә. Дөрес, әле алар төзелеш эшләренә, малларны сатып

алырга узләренең 800 мең сум акчасын тоттылар,ә инде бөтен документларын эшләп тапшыргач, дәүләт программасына керәчәкләр.

Шулай ук Шарипов Ильшат берничә кешенең пай жирләрен оформить итеп берләштереп 2012 елда бик әйбәт кенэ эшләп китте.

Бу җирләргә арпа, бодай чәчеп хужалыкларга житәрлек уңыш алды,жирнең бер өлешенә көздән арыш чәчеп куйды. Жир эшкәртергә, урырга бөтен техникасы бар. Кышкы айларда урман сатып алып узенең пиларамында материал чыгарып табыш ала,бура бурап сата,2 магазины бар.Бу семьяда тик ятучы юк,кызлар да , кияуләр дә барсы да эштә.

Безнең авыл җирлеге табигате урманга бай булгангадыр инде кортчылык бик алга киткән : Шарипов Фәнис, Шарипов Илхам,ШакировИлхам, Хөснетдинов Фәрит, Нараттан Муллахметов Рафаэль, Газизов Сәгыйтләр бик күп табыш алалар. Бездә житештерелгән бал сыйфатлы һәм файдалы, шуңа курә аны сатуда кыенлыклар юк,кайберләрнең хаттә Мәскәүдә сату урынлары бар.

Алда санап киткән эшләрне башкарыр очен,хужалыкларны алып барыр өчен бездә техникасы да житәрлек иптәшләр:

МТЗ-80,82—13 штук

ДТ-75 тракторы-4 штук

Т-25 – 6 штук

Т-40-2 штук

ГАЗ,ЗИЛ -9шт.

Тагылма техникалар да житәрлек. Алга таба пай жирләрен оформить итеп печән чәчеп, ашлык устереп табыш алырга мөмкинлек бар.

Девятерня , Нарат авылларында сөт жыю пунктлары эшли.Шакирова Зөлфирә,Фахриева Раушаниялар бу эшкә бик жаваплы карыйлар,вакытында акчасын алып тиешенчә халыкка расчет ясап баралар.Иң күп сөт тапшыручы хужалыклар: Зарипова Рәзилә-7450 литр, Фахриева Раушания 5100литр, Девятернядан Гарифуллин Рифкат ,Сибятов Инсаф, Бакиров Камил семьялары сөт тапшырып остәмә табыш алалар .Ә

кайбер хужалыклар эремчек ясап май язып базарда сатуны кулайрак күрәләр.

Хөрмәтле гражданнар! Авыл җирлегендәге эшчәнлекне алып барыр өчен еллык бюджет , внебюджет төзелә. Бюджетка җир налогы, җир милек(имущественный) налогы, зарплата, коммуналь түләүләр, ГСМ һәм башка чыгымнар керә. Ә внебюджетка суга жыелган акча, үзара салым акчасы, платные услуги(СДК) акчасы, авылны төзекләндерү ,су белән тәэмин итү , ремонтлау, насос сатып алу, бәйрәмнәр, чаралар үткәрү өчен тотыла . 2012 елга : суга 71750 сум, үзара салым- 18000 сум жыелды. Бу акчалар нәрсәгә тотылды соң?- 67720 сум- су башнясы, электр энергиясенә, яңа насос алырга -22600 сум, насос ремонтына- 8600сум. Җыелган налог акчалары саклык банкына тапшырыла, үзәк бухгалтерия аркылы расходка чыгарыла. Суга , үзара салым акчасы жыйганда төрле кыенлыклар килеп чыга. Түләмәс өчен төрле сәбәпләр табалар.Түләмәүчеләр исемлеге бар. Бу исемлекне магазиннарга, белдерү тактасына элеп куячакбыз, кирәк икән район газетасына да бастырачакбыз.

Авылда халыкны су белән тәэмин итүдә өзеклекләр юк диярлек. 3 ел эшләү дәверендә 700 метр дан артык ике су магистральләре алыштырылды. Элеке мол. комбинат башнясы авыл магистраленә тоташтырылды. Янадан Девятерня авылында 200 метрдан артык магистраль алыштырасы бар. Быел да мөмкинчелекләрдән чыгып ремонт эшләрен дәвам итәрбез дип ышандырам. Нарат авылында эшләр четреклерәк. Су системасы тыгылып беткән. Бик күп чыгымнар таләп итәчәк. Узебезнең кулдан килгәнчә эшләргә тырышабыз. 2012 елда 1 км. озынлыкта торбалар суздык, ләкин моның белән генә проблеманы чишеп булмый. Ришат Тимерович , Сезнең ярдәмегез белән бу проблеманы ничек тә хәл итәргә кирәк. Гали авылында бөтенләй су системасы юк. Андый авыл районда бездәгенәдер инде . Барлык Гали авылы халкыннан Валерий Владимирович исеменә хат язып карасак ничек булыр икән, Ришат Тимерович?

Авыл җирлегендә иң зур проблемаларның берсе- чисталык мәсьләсе. Махсус чүп түгү урыннары билгеләнгән булса да, кайбер хужалыклар теләсә кая чүп түгә, мал суя, малларны көтүгә чыгармыйча теләсә кайда йөртә, кисәтугә карамастан .Аллага шөкер ,уңай якка узгәрешләр бик күп, халык аңлый, авылларыбыз матурлана , чистара , яшәүләре куңелле.

Соңгы 2-3 ел эчендә зыяратларга игътибар арта. Мэнгелек йортыбызда чисталык, тәртип булдырыла. 3 авылда да зыяратларны чистартуда куп эшләнде. Девятерняда 800метр койма яңартылды, узган ел жыены карары белән халыктан 35 мен 500 сум акча жыелды. Сезгә бик зур рәхмәт әйтәсе килә авыл җирлеге исеменнән. Шул ук вакытта акча бирмәучеләр дә бар . Шушы бирелмәгән сумманы жыйсак, быелгы ремонтка акча житәчәк. Мәчет һэм зыярат акчасы жыюны Сабирҗан абый бик төгәл алып бара,( төрле сүзләр ишеттерсәләр дә). Мәчетне, зыяратны тотуда аның өлеше зур. Гали зыяратына 100 метрга житәрлек материал алынды, бу эш быел эшләнәчәк. Өмәдә актив катнашкан Бакиров Камил , Сабиржан абый. Шарипов Илшат, Шакиров Әнвәр, Гатауллин Рафис, Гыйлфанов Рифкат, Закиров Рамил, Шарипов Асфан, Гарифуллин Рифкат, Шарипов Фанис, Ясавиев Илфат, Мингазов Минегаяз , Арсланов Фәнис хэм башка иптәшләргә зур рәхмәт.

Девятерня авылы өчен 2012 елда тагын бер зур эш эшләнде :Советская урамындагы асвальт юл бик начар хәлдә иде . БРУС ширкәте житәкчелеге белән килешенеп, 800 метр юлны ремонтладык,акчага әйләндергәндә 350 мең сумлык эш башкарылды. Халык исеменнән БРУС ширкәтенә Зур рәхмәтебезне житкерәбез.

Кадерле иптәшләр! Авыл жирлегендә халыкка томыш- көнкүреш итү өчен бөтен унайлыклар, мөмкинлекләр тудырылган .Культура,медицина, белем бирү үчреждениеләре бар. 5 магазин, почта булеге халыкка хезмәт курсәтә.

Девятерня урта гомумбелем биру мәктәбе коллективында 15 укытучы, 2 тэрбияче,13 тех персонал эшли, 66 бала белеем ала.Балалар бакчасында 12 бала тэрбиялэнэ.Куп кенэ укытучыларыбыз мактаулы исемнэргэ ,булэклэргэ ия: 2 укытучы-югары категорияле.8-беренче катег..1-2 категорияле. 4 укытучы уз вазифаларына туры килу буенча аттестация утте. 12 укытучы – югары , 3се махсус урта белемгэ ия. Шуна курэ укучыларыбыз да торле олимпиадаларда, конкурсларда,спорт ярышларында алдынгы урыннар яулыйлар. Девятерня мэктэбенен алдагы 5.6 елга прогнозы эйбэт, балалар саны стабиль саклана. Мэктэптэ бик эйбэт коллектив тупланган. Алдагы елларда да шушы составта эшлэргэ язсын иде .

Шулай ук, Нарат авылында мэктэп- бакча эшлэп килэ. Барлык унайлыклар , шартлар тудырылган. Коллектив тупланган. Матур гына эшлэп килэлэр:3 бала укый, 6 бала бакчага йори.

Фельдшер- акушерлык пунктлары ике авылга хезмэт курсэтэ. Авыл жирендэ ин тынгысыз эш аларныкы дияр идем. Медик кызларыбыз уз эшлэренен остасы. .эш урыннарында халыкка ярдэм итэр очен барлык унайлыклары тудырылган. 3 авыл халкы да алар эшеннэн канэгат.

Почта булеге 3 авылга хезмэт курсэтэ, 2 кеше эшли.Алар тарафыннан пенсиялэр. Субсидиялэр график нигезендэ бирелэ. Газета журналга язылу буенча планнар утэлэ. Янгыр. кар явуга карамастан ойлэребезгэ вакытында таратыла. 2012 елда барлыгы19 млн. сумга якын пенсия таратылган. 1млн.800 мен сумлык субсидия бирелгэн.

Бугенге кондэ авыл жирлегендэ 5 магазин халыкка хезмэт курсэтэ, аллага шокер магазиннарда барлык товарлар да житэрлек, һэрвакыт свежий товар кайтартыла .Халык бик канэгат, рэхмэтле. Авыл халкының бер генэ телэген житкерэсем килэ, эш графигы буенча эшлэсеннэр иде.

Культура хезмэте курсэтудэ Девятерня Мэдэният йорты,**На**рат авыл клубы эшлэп килэ.Барлык бэйрэмнэр. Чаралар алар житэкчелегендэ уткэрелэ. Сонгы елларда авылыбыз узешчэнлэре концертларда бик актив катнашалар.Купме талантларыбызны без белмэгэнбез икэн. Фаррахова Рэмзия, Ситдикова Голсинэ, Ахметзянова Рэйсэ, Шакирова Золфирэ, Ахмедьянова Элфия, Шарипова Голия,Файзуллина Золфия,Гатауллина Голшат, Мусифуллина Нурия, Фатхетдинова Галия апаларыбыз Казан артистларыннан да остарак ич.Рэхмэт сезгэ. Алга таба да шулай дэвам итегез.

Хормэтле гражданнар! Авыл жирлеге ел эйлэнэсе халык ярдэме белэн һэм халык очен эшли. Халык белэн эшлэу дэверендэ куп кенэ проблемаларны чишеп барабыз. Авылларда урамнар яктыртылган, чуптэн, кардан вакытында чистартылып бара. Калган житезсезлеклэр остендэ эшлибез .

Ярдэм кирэк булса сорар кешелэребез бар: Нефтебаза директоры авылдашыгыз Ирек Рафаэлевич һэрвакыт ягулык белэн ярдэм итеп тора .Быел гына да 13 менлек солярка бирде. Югары урамга су керткэндэ депутат буларак 20 мен сумлык ярдэм итте. Трактор белэн ярдэм кирэк булса Шарипов Илшат ,Шакиров Әнвәр абыйларга мөрәжәгат итәбез, Ак Барс

агрофирмасы Нарат булекчэсеннэн Тимершин Илшат, Расулов Фэриллэр булышлык курсэтэ, машина кирэк булса, Бакиров Муллаян абый һэрвакыт ярдэмгэ килэ, бэйрэм чаралары уткэргэндэ Шарипов Илшатнын юмарт кулын тоябыз. Барыбыз исеменнэн дэ Сезгэ зур рэхмэт.Аллага шокер,менэ шулай бергэ- бергэ эшлэп ,яшэп ятабыз .

Чыгышымның азагында, барыгызны да бугенге изге мәулид бәйрәме белән котлыйм, саләмәт булыйк, гаилэлэребездэ тынычлык, татулык булсын, килэчэккэ омет белэн яшик!

Алдагы елларда да шулай бергэ очрашырга язсын!!

Игътибарыгыз очен зур рэхмэт!!!